Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советының утыз өченче утырышы

Күнавыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

19 апрель, 2024 ел № 90

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Күн авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Күн авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә (Советның 2023 елның 31 мартындагы 63 номерлы, 2023 елның 30 октябрендәге 78 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 82 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 8 статьяның 4 өлешендәге 11 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11.2 пунктча өстәргә:

«11.2.) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр, аларга федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы төзи;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов